# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге составына керүче Бохар торак пунктында узган гражданнар җыены карары

16 ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге составына керүче Бохар торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының Урмышлы авыл җирлеге составына керүче Бохар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, тыл хезмәтчәннәреннән, күп балалы гаиләләрдән тыш, 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Әлеге средстволарны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә:

- юлларны карап тору һәм ремонтлау.

Гражданнар җыелышында рәислек итүче,

Урмышлы авылы җирлеге башлыгы А.Ф.Хәбибуллин